ГЛАВА УТЯШКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Центральная, д. 10,
с. Татарское Утяшкино, 423186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ӘДӘМСӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк урамы, 10,
Әдәмсә авылы, 423186

тел., факс: (8-4348) 38-7-41,Ut.nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

от «30» сентября 2024 года | № 5

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлегендә Бакташ авылында халык җыенын билгеләү турында гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елның 18 октябрендә 10.00 сәгатькә Кояш урамындагы 9 нчы йорт янында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлегенең Бакташ авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенын үткәрү өчен татар Әдәмсә авылында яшәүчеләр исемлеген бүлүне сайлау тәртибен вакытлыча билгеләр буенча башкарырга.
3. Гражданнар җыены этапларын үткәрүне һәм оештыруны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлеге башлыгы тәэмин итә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлегенең Бакташ авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Россия Федерациясе Кораллы көчләренең контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләреннән, мобилизацияләнгәннәрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлеге Бакташ авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы?
Түбәндәге эшләр:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү);

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (контейнер мәйданчыгын төзекләндерү, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү).

«ӘЙЕ» «ЮК»».

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмати – телекоммуникация челтәрендә: http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): http://novosheshminsk.tatarstan.ru/, мәгълүмат стендында Бакташ авылы, Кояшлы урамы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы 7-нче йорт янында гражданнар җыены уздырылганчы 10 көннән дә соңга калмыйча

6. Әлеге карар аның басылып чыгуыннан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Әдәмсә авыл җирлеге башлыгы А.И. Назмутдинова